

Агымдагы елнын 17-19 августында Мордовиябездә «Без бергә!» Ботенроссия яшьләр милли мәдә-ниятләр фестивале vтте. Чарада утыз биш регионнан делегатлар катнашты. Эчтәлекле программанын икенче конендә, ягъни 18 августта, Советлар мәйданында (Советская площадь) «Халык сәнгате йолдызлары» («Звёзды народного искусства») Арт-марафонында булырга насыйп иде.
Программа буенча республика артист-ларынын музыкаль сәламләве «Шумбрат, фестиваль!» белән башланып китте. Аннары Краснодар шәһәренен «Скрыня» ансамбле чыгышы, Владимир шәһәренен «Владимирские рожечники», Удмуртия жыр һәм бию театры «Айкай» һәм Татарстаннан безгә якын булган «Агыйдел» («Агидель») Дәvләт татар жыр һәм бию ансамбле чыгыш ясадылар.

«Агыйдел» белән танышабыз. Дәvләт татар жыр һәм бию ансамбленын тарихы 1966 елдан килә. Муса Жәлил исемендәге премия лауреаты (1990), vзешчән сәнгатьтә катнашучыларнын Ботенсоюз фестивальләре лауреаты «Агыйдел» жыр һәм бию ансамбле 2012 елдан Дәvләт ансамбле исемен йортә. Ансамбль составында (23 балет артистыннан, 12 хор артистыннан башка) «Мизгел» бию ансамбленын олкән, урта һәм кече торкемнәре, ветераннарнын бию ансамбле, катнаш вокал, ирләр вокал, хатын-кызлар вокал ансамбльләре, «Фируми» триосы, халык уен кораллары ансамбле эшли. Коллектив тулысынча һонәри жырчылар, һонәри биючеләрдән тупланган. Ансамбль директоры ТР атказанган мәдәният хезмәткәре Лилия Мәvләви кызы Ялалова, сәнгать житәкчесе Лилия Равил кызы Фәтхуллина, режиссер-куючы Инсаф Әхнәф улы Хәбибуллин, балетмейстеры Булат Юнер улы Госманов. Бер сvз белән әйткәндә, бу коллективны Россия гына тvгел, чит ил халкы да белә.
Кvп еллар дәвамында «Агыйдел» татар халкынын фольклор тра-дицияләрен пропагандалый һәм концерт программаларында, ижади очрашуларда, фестивальләрдә, Россия шәһәрләрендә, шулай ук Торкиядә, Торкмәнстанда vткән конкурсларда югары дәрәжәдәге вокаль-хореография сәнгатен һәм актерлык осталыгын кvрсәтә. Шулай, 18 августта башкалабызнын Совет мәйданында, Коваленко урамындагы мәйданда (Саранскнын Пролетар районы) чыгыш ясагач, югарыда санап киткән унышларына дәлилне кvрдек. Бигрәк матур чыгышлары булды: баштан азакка кадәр алкышларга кvмелеп барды.
Мина ансамбльгә Дәvләт жыр һәм бию исеме бирелгәннән алып директоры булган Татарстаннын атказанган мәдәният хезмәткәре Лилия Мәvләви кызы Ялалова белән әнгәмә корырга момкинлек булды. Ул Мордовия һәм фестиваль турында:
- Ботенроссия яшьләр милли мәдәниятләр «Без бергә!» фестивале - Ватаныбыз тарихы, анда яшәvче милләтләр һәм Ватаныбыз Россия бай булган гореф-гадәтләр турында сойләшергә искиткеч момкинлек. Бу бәйрәм ата-бабаларыбызнын кvп гасырлык традицияләрен, боек илебезнен зур мәдәни мирасын хормәт итv. Татарстаннын Актаныш

районы вәкилләре буларак, милли vзенчәлекләрне сәхнәдә kvрсәтергә тырышабыз.



- Мордовиядә vткән ел узган Ботен-россия авыл Сабантуенда булдык. Менә бу чарада да катнашабыз. Мин Мордовия халкына хас булган биредәге кунакчыллык, ярдәмчеллек сыйфатларына сокланам; топ vзенчәлегегез - ачык кешеләр. Бу кыйммәт һәм хөрмәткә лаек сыйфатларнын берсе.
«Агыйдел» Дәvләт жыр һәм бию ансамбле чыгышлары арасында яшь биючене фотога тошерегә дә олгердем. Ботенроссия яшьләр милли мәдәниятләр фестивалендә сәләтле киләчәк буыннын алдагы коннәре матур булсын, унышларга торенсен!
19 августта Мордовиянен татар районы булган Ләмберәнен «Алмаз» мәдәният һәм спорт сараенда да «Агыйдел» Дәvләт жыр һәм бию ансамбле чыгышлары белән халыкнын kvнеленә хуш килде.



Фестиваль ижади коллективлар һәм башкаручылар чыгышы белән дәвам итте. Аннары сәхнәдә Дагестаннын «Гергебиль» халык вокаль-хореография ансамбле чыгыш ясады. Ярты гасырдан артык бу ансамбль халык kvнеленә шатлык алып килә. Артистларнын колоритлы чыгышы Дагестан халыкларынын барлык торлелеген һәм матурлыгын kvрсәтә. Гергебиль районынын «Гергебиль» халык хореография ансамбле яндыргыч хореографик номеры белән чыгыш ясады.

Сәхнәдә артистлар үзләренен традицион костюмнарын, гореф-гадәтләрен, мәдәниятен биюләрен жырлар аша тәкъдим итеп, якты калейдоскоп белән алыштырылды.
Уфа шәһәренен «Аманат» башкорт халык биюләре ансамбле чыгышы аерым игътибарга лаек. 2019 елда оештырылган коллектив эшләү дәверендә билгеле бер ижади унышларга иреште. Коллективнын репертуары янадан-яна биюләр белән янарды. Анда башкорт биюләре һәм донья халыкларынын биюләре бар. Бу коллектив Ботен-россия, Башкортстан, тобәкара конкурсларда һәм фестивальләрдә катнашып зур дәрәжәле мәдәни проектлар лауреатлары булдылар. Житәкчеләре - «Мирас» фольклор жыр һәм бию ансамбле солисты Әнфәр Нурмохәммәтов, халыкара һәм Ботенроссия конкурслары лауреаты Нәзифә Нурмохәммәтова. Бәйрәм концертында коллектив үз репертуарыннан ин яхшы номерларны, башкорт халык биюләрен һәм донья халыкларынын биюләрен күрсәтте. Алар 19 августта Кочкурово районы халкын эчтәлекле һәм матур чыгышлары белән шатландырды.
Ботенроссия яшьләр милли мәдә-ниятләр фестивален ачу тантанасы «Без бергә!» белән башланса, театральләштерелгән пролог «Без Россия белән бергә!» иде. Фестиваль Россия халыкларынын матди булмаган мәдәни мирасын саклауга һәм халыкнын кин катламнарынын, беренче чиратта талантлы балалар һәм яшьләрнен үз-үзләрен белдерүенә һәм тормышка ашыруына ярдәм итүче ижади инициативаларга булышуга юнәлдерелгән.

**Наилә НАСЫРОВА**